Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

12 декабрь 2022 ел № 184

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 25 апрелендәге 375 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы ниезендә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вазыйфаларны һәм вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын булдыру буенча үзара эшчәнлекне оештыру турында төзелгән Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә

Әлмәт муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2014 елның 25 апрелендәге 375 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турында»гы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 23 сентябрендәге 7 номерлы, 2017 елның 31 маендагы 185 номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 203 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 255 номерлы, 2020 елның 12 мартындагы 368 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 3 пунктында «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

1.2. карарга1 нче кушымтада:

- 10 пунктта «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар һәм бүләкләр бүлегенә.» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының кадрлар сәясәте бүлегенә.»;

- 14 пунктта «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советы» сүзләренә алмаштырырга;

- 32 пунктта «,Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар һәм бүләкләр бүлеге» сүзләрен «, Әлмәт муниципаль районы Советының кадрлар сәясәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

- 45 пунктта «Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар һәм бүләкләр бүлеге» сүзләрен «Әлмәт муниципаль районы Советының кадрлар сәясәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. карарага 2 нче кушымтада:

- 19 пунктта «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар һәм бүләкләр бүлеге.» сүзләрен «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының кадрлар сәясәте бүлеге» сүзләренә алмаштырырга.»;

1.4. карарга 3 нче кушымтада:

а) комиссия составыннан М.М. Насертдиновны чыгарырга;

б) комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

- Белоногов О.Т. - Әлмәт муниципаль районы Советының кадрлар сәясәте бүлеге җитәкчесе, комиссия секретаре;

- Ганиева Р.И. - Әлмәт шәһәренең халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры, комиссия әгъзасы (килешү буенча);

в) комиссия әгъзалары вазыйфаларын яңа редакциядә бәян итәргә:

- Ханнанова Ә.Б. - Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге җитәкчесе;

- Алеева Ә.Р. - Әлмәт муниципаль районы Советының кадрлар сәясәте бүлеге җитәкчесе  урынбасары;

- Мусин Р.Ф. Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәр Советы депутаты (килешү буенча).

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник»» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә  урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советеның з аконлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Парфилова Н.А.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов